Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

# КАРАР

21 май 2024 нче ел №16

Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрель 10 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрель 10 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 07 ноябрендәге 29 номерлы, 2019 елның 17 маендагы 10 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 7 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 6 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 20 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 3 номерлы, 2023 елның 31 октябрендәге 25 номерлы, 2023 елның 20 декабрендәге 35 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 нчы бүлекнең 3.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 12 нче пунктча белән тулыландырырга:

«12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында һәм әлеге Нигезләмәнең 11.1 бүлегендә каралган анкетада булган мәгълүматларның, яллаучы вәкиле (эш бирүче) карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан (алга таба – анкетада булган мәгълүматлардан) тыш, аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә .»;

1.2. 8 бүлекнең 1 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яки) аны үткән вакытта муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулаучы чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы ялган документлар һәм (яки) күрәләтә ялган мәгълүматлар тәкъдим итү яисә яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында документлар һәм (яки) мәгълүматлар тапшырмау;»;

1.3. түбәндәге эчтәлектәге 11.1 бүлеге өстәргә:

«11.1. Анкета тәкъдим итү, анкетада булган мәгълүматларның үзгәрүе турында хәбәр итү һәм мондый мәгълүмаларны тикшерү

1. Муниципаль хезмәткә кергәндә, гражданин анкета тәкъдим итә.

2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

3. Анкета формасы, шул исәптән аңа кертелгән мәгълүматлар исемлеге, аларны яңарту тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4. Анкетада булган мәгълүматлар яллаучы вәкиле (эш бирүче) яки аның вәкаләтлесе карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган мәгълүматларны тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган иҗтимагый хакимият органнарына һәм оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, соратулар җибәрү юлы белән башкарыла.»

1.4. 12 нче бүлектә:

1.3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында һәм әлеге Нигезләмәнең 11.1 бүлегендә каралган анкета;»;

1.4 пункт «Мәгълүматлар» сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.5. 25 бүлекнең 1 пунктындагы 118 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль хезмәткәр аны үткән вакытта граждан тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хәнәфиев